КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 27 апрель г.Казань № 547

2026 – 2028 елларда Татарстан Республикасында оборона-сәнәгать комплексы оешмалары ихтыяҗлары өчен һөнәри укытуны һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру турында

«Кадрлар» илкүләм проекты составына керә торган «Хезмәт базары өчен мәгариф» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган «Хезмәт базары өчен мәгариф (Татарстан Республикасы)» төбәк проекты кысаларында оборона-сәнәгать оешмаларын кирәкле квалификациядәге кадрлар белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2026 – 2028 елларда эш бирүчеләрнең оборона-сәнәгать комплексы оешмалары ихтыяҗлары өчен белем бирүне оештыру чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен эш бирүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарны куллану буенча аңлатмалар бирү Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2025 елда Татарстан Республикасында оборона-сәнәгать комплексы оешмалары ихтыяҗлары өчен һөнәри укытуны һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру турында» 2024 ел, 27 апрель, 285 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елда Татарстан Республикасында оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре (оешмалары) ихтыяҗлары өчен һөнәри укытуны һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру турында» 2024 ел, 27 апрель, 285 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 ел, 8 апрель, 204 нче.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин